| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>МЕНДЕЛЕЕВСКИЙ<br>ГОРОДСКОЙ СОВЕТ<br>МЕНДЕЛЕЕВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>МЕНДЕЛЕЕВСК ШӘҺӘР<br>СОВЕТЫ |
|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2021 елның 13 апреленнән № 17

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районының
«Менделеевск шәһәре» муниципаль берәмлегенең
җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә
үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының «Менделеевск шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставы белән, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының «Менделеевск шәһәре» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм уздыру тәртибе турында нигезләмә белән, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының 2010 елның 4 октябреннән 142 номерлы җирле үзидарә советы тарафыннан расланган Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының «Менделеевск шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре, 2021 елның 7 апреленнән 1 номерлы беркетмә һәм ачык тыңлаулар бәяләмәсе нигезендә,

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Менделеевск шәһәр Советы **КАРАР БИРӘ:**

1. 2010 елның 4 октябреннән 142 номерлы Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Менделеевск шәһәр Советы карары белән расланган Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының «Менделеевск шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 39 статьяның «Шәһәр төзелеше регламентлары. Торак зоналары» «Ж-1. Шәхси утар торак төзелеше зонасы» территориаль зонасына түбәндәге эчтәлекле пункт өстәргә:

«Җир кишәрлекләренең иң чик күләмнәре:

«Шәхси торак төзелеше», «шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен» рөхсәт ителгән куллану рәвешендәге җир кишәрлекләренең минималь күләме - 1 000 кв.м.

«Шәхси торак төзелеше», «шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен» рөхсәт ителгән куллану рәвешендәге җир кишәрлекләренең максималь күләме - 2500 кв.м.».

1.2. 41 статьяның 23 абзацында «АГЗС» сүзләреннән соң «, АГНКС» сүзләрен өстәргә.

1.3. 42 статьяның 12 абзацында «АГЗС» сүзләреннән соң «, АГНКС» сүзләрен өстәргә.

1.4. 1 нче кушымтада «Менделеевск шәһәре» муниципаль берәмлегенең шәһәр төзелешен зоналаштыру картасы»:

а) элеккеге йорт төзү комбинаты территориясе һәм аның янәшәсендәге территория өчен 1 нче кушымта нигезендә II-III класслы зыянлылык (ПК–1) җитештерү-коммуналь объектлар зонасын урнаштыру;

б) кадастр номерлары 16:27:020601:764, 16:27:20601:828, 16:27:20601:1046, 16:27:20601:745 һәм аның янындагы территорияләр өчен транспорт инфраструктурасы объектлары зонасын (Т1) 2 нче кушымта нигезендә билгеләргә;

в) 3 нче кушымта нигезендә «Идел» М-7 автомобиль юлыннан Ижевск һәм Пермь шәһәренә килү» автомобиль юлы буйлап урнашкан территория өчен транспорт инфраструктурасы объектлары зонасын билгеләргә.

1.5. 40 статьяның «Шәһәр төзелеше регламентлары. Торак зоналары» «Д-2. Сәламәтлек саклау һәм социаль билгеләнештәге объектларны урнаштыру зонасы» территориаль зонасын «физкультура-савыктыру корылмаларын» файдалануның рөхсәт ителгән төп төре белән тулыландырырга.


2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга һәм Россия Федерациясе территориаль планлаштыруның Федераль дәүләт мәгълүмат системасында расланган документны урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Менделеевск шәһәр Советының икътисад, торак-коммуналь хуҗалык һәм төзелеш буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Советы рәисе В.С.Чершинцев


1 нче кушымта

«Менделеевск шәһәре» муниципаль берәмлегенең
шәһәр төзелешен зоналаштыру картасы» кушымтасы фрагменты



2 нче кушымта

«Менделеевск шәһәре» муниципаль берәмлегенең
шәһәр төзелешен зоналаштыру картасы» кушымтасы фрагменты



3 нче кушымта

«Менделеевск шәһәре» муниципаль берәмлегенең шәһәр төзелешен зоналаштыру картасы» кушымтасының фрагменты

